**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

№87-РС от 28.08.2023 г.

# КАРАР

«Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе турында»Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 23 декабрендәге 103-РС номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль Закон һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы Уставы нигезендә КАРАР ИТТЕ:

1. «Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 23 декабрендәге 103-РС номерлы карарына, 2.1.2 пунктның 3.7 пунктчаларын түбәндәге абзац белән тулыландырып, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарга һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарга үз инициативасы белән бирергә хокуклы;

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Башлык – муниципаль район
Советы Рәисе И.Ф. Зарипов